Даутов Г.Ф.,
Хәйруллина Ә.С.
Казан федераль университетының
Алабуга институты

# МИЛЛИ ТӘРБИЯНЕҢ ЧИШМӘ БАШЫ

«Без тарихта эзлебез» - шагыйрьнең бу сүзләре тирән тарихи мәгънә салып әйтелгәннәр. Һәр халык, һәр милләт нинди дә булса җепләр һәм юллар белән гомумкешелек яшәешенә тоташа, әмма шул ук вакытта аның үзенә генә хас иҗтимагый үсеш юлы, тормыш-көнкүреше һәм үткән тарихи юлы бар. Бер халыкта икенче халык язмышын төгәл тәңгәл килерлек итеп кабатламый, ниндидер охшашлык булса да, халыкның үзенә генә хас булган психологик төсмерләре, яшәеше белән үткәндәге тарихи юлы белән бәйле милли сыйфатлары аны үзенчәлекле һәм кабатланмас итә. Яшь буынны чорның афәтле җилләреннән саклап калу өчен әнә шул милли сыйфатларга нигезләнгән тәрбиягә мөрәҗәгать итү кирәк. Күп гасырлык традицияләрне, милли-мәдәни кыйммәтләрне саклау, аларны алга таба да үстерү заманның күп кенә икътисадый һәм иҗтимагый проблемаларын чишәргә ярдәм итәчәк. Моның өчен бүгенге фәнни анализ методларын кулланып үткәндәге педагогик тәҗрибәне карап чыгу һәм үзләштерү таләп ителә.

Тәрбия бирү белән бергә җәмәгатьчелек алдына белем бирү һәм мәгариф эшен яхшырту проблемасы да килеп басты. Фән-техник революциянең тизлек белән үсүе аркасында мәгариф үз алдына куйган бурычларны тиешенчә үти алмый башлады һәм бу хәл күп тикшеренүчеләрнең, методист-укытучыларның, педагогларның игьтибар үзәгендә тора. Хәзерге татар халкының хаксызга кире кагылган, онытылган мирасына игьтибар артты. Татар тарихы объектив яктыртыла, әллә нинди ярлыклар белән тамгаланып чит илгә китәргә мәҗбүр ителгән язучыларыбызның әсәрләре халыкка кайтарыла, төрле сәяси карашларда торган иҗтимагый эшлеклеләребезнең тормыш юлын, милләт үсешенә булган карашларын яктырткан мәкаләләр дөнья күрә. Ләкин болар әле

барлык ихтыяҗларны да канәгатьләндерерлек түгел. Тарих фәнендә ачыкланмаган мәсьәләләр, ак таплар җитәрлек, күп кенә язучыларның әдәби мирасы да киң катлам укучыга җиткерелмәгән. Милли мәдәниятне, аның күп гасырлык традицияләрен өйрәнүнең әһәмиятен аерым сөйләп тору артык эштер. Югарыда инде бер кат әйтелгәнчә, элгәреләрнең тәҗрибәсен куллану бүгенге көннең күп кенә проблемаларын хәл итәгә һәм күп кенә хаталарны булдырмаска мөмкинлек бирә. Халыкның күп гасырлар дәвамында эшләнгән һәм үсеп килүче буынны тәрбияләргә юнәлтелгән мораль, этик һәм эстетик норма кагыйдәләре бар. Һәр язма әдәбиятның чишмә башында, һәр язучының иҗат нигезендә халык фольклоры яткан кебек, һәр педагогик тәгълиматның асылын халыкның тәрбияви традицияләре тәшкил итә.

Педагогик мирасны өйрәнгәндә беренче чиратта, бервакытта да кыйммәтләрен, актуальлекләрен югалтмый торган сыйфатларга һәм шуларга нигезләнгән закончалыкларга игътибар итәргә кирәк. Үзенчәлекле тарихи үсеш нәтиҗәсендә татарларда педагогик фикер XIX гасыр азагы XX гасыр башында формалаша. Күренекле мәгърифәтче педагоглар үзләренең фикерләрен халыкка җиткерү өчен матур әдәбиятны корал итеп алалар. 1905 елгы революция ачкан мөмкинлекләрдән файдаланып, татарлар вакытлы матбугат булдыруга ирешәләр. Бу педагогик фикерне яңа теоретик биеклекләргә күтәрергә мөмкинлек бирә. Татар педагогикасы фәне, аның педагогик нигезләре конкрет төсмерләр ала.

XIX гасыр азагы XX гасыр башы ул, гомумән, татар иҗтимагый тормышында үзекчәлекле урын алып торган чор. «XIX гасыр азагы XX гасыр башы татар милләте өчен чын мәгънәсендә Ренесанс чоры була. Әдәбиятта, мәдәниятта иҗтимагый тормышта яңарыш шул кадәр кечле була ки, моны борынгы Рим, Юнан дәүләтләренең яңарышы белән чагыштырырга мөмкин» [4].

Мәгърифәтче галимнәр, бүгенге халәтне дөрес бәяләр өчен:

- тарихка, үз идеяләрен халыкка җиткерер өчен - әдәбиятка, заман таләпләренә җавап бирердәй буын үстерер өчен - педагогикага мөрәҗәгать итәләр.

Әлеге мәсьәләдә продуктив һәм күпкырлы эшчәнлеге белән Р.Фәхретдин иң күренекле урын алып тора. Әдәби әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар, фәнни хезмтәләрендә тикшерелгән мәсьәләләр иҗтимагый тормышның бар якларын да колачлыйлар. Бер үк вакытта тарихчы да, әдип тә, журналист та, дин эшлеклесе дә, педагог та булган бу олуг шәхес эшчәнлеген М.Госманов « .. гаять эчтәлекле, күпкырлы, тирән мәгънәле тарихи күренешләрнең берсен тәшкил итә» дип бәяләве белән мең кат хаклы.

Татарстан республикасының Әлмәт районы Кичү Чаты авылында 1859 елда туып, башлангыч белемне башта үз авылында, аннан күрше Түбән Чыршылыда алган Ризаэтдин Фәхретдин, еллар үтү белән бөтен дөньяга билгеле олуг галим булып җитешә. Шәкертлек гомеренең зур күпчелеген, ун елга якын вакытын булачак әдип-галим күрше авыл булган Түбән Чыршылыда уздыра. «Шул чордагы башлангыч белем бирүне тасвирлап, соңыннан болай дип яза: «Мәхәлләләрдә булган ир балалар мәхәллә мәктәбе дип йөртелгән мәктәпләргә йөреп укыйлар, укытучылар шул мәхәлләнең имамы буладыр иде. Кыз балалар имамнарның өйләренә сабакка йөреп, шул имамнарның хатыннарыннан (остазбикәләрдән) укыйлар иде. Дәресләр күп вакытта октябрь башыннан башланып, март ахырларында тукталадыр иде». Әлеге язмасында ул кайсы фәннәрнең ничә кыш укытылганын күрсәтеп (55 фән, 16 кыш), мәдрәсәнең соңгы сыйныфында укучыларны «сакаллы шәкертләр» дип атый [8].

Шул ук шәкертлек елларында Р.Фәхретдиннең дөньяга карашларын үзгәртеп җибәргән бер вакыйга була. Белгәнебезчә, бу чор искелек белән яңалыкның көрәше буларак кадимчеләр һәм җәдитчеләр хәрәкәте киң җәелгән вакыт. Халыкның аң-белемен күтәрер өчен яңа укыту ысулын пропагандалаган җәдитчеләргә каршы кадимчеләр киң колачлы һөҗүм алып баралар.

Р.Фәхретдин кулына очраклы рәвештә җәдитчеләрнең идеологы дәрәҗәсендә йөргән Ш.Мәрҗанинең атаклы фәлсәфи хезмәте "Назурател - хак…» ны тәнкыйтьләп кадимчеләр тарафыннан бастырылган «Җарүдә..» китабы килеп керә. Эзләнүчән табигатьле, кызыксынучан яшь галим, ике китапны чагыштырып карау максаты белән «Назурател - хак...» ны табып укый... һәм, тулысынча Мәрҗани карашларын дөрес дип кабул итеп, гомеренең ахырына кадәр аның йогынтысы астында иҗат итә. «...Һәрхәлдә Мәрҗанине тануыма беренче сәбәп «Җарүдә..» булды. Шул көннән игьтибарым Мәрҗанинең һәрбер матбуг әсәрләрен тәкъкыйб итеп тордым вә бик күп истифад кылдым», дип күрсәтә галим Ш.Мәрҗанинең 100 еллыгына багышлап чыгарылган җыентыктагы мәкаләсендә.

Тормышындагы икенче борылыш, 1898 елны Уфага күчеп килеп, Диния нәзаратында казыйлык вазыйфаларына тотынгач була. «Чөнки нәзаратта эшли башлау Фәхретдиновка анда җыелган бихисап кул басма һәм язма китаплар, төрле мөселман илләрендә чыккан гарәп, фарсы, төрек газета-журналлары белән системалы рәвештә танышып бару мөмкинлеге тудыра... Риза казый нәзараттагы китап хәзинәлегеннән максималь рәвештә файдалана. Моңа ул аңар хәтле тәртипсез рәвештә өелеп яткан китапларның һәрберсен карап чыгу, аларны яңа баштан каталоглау, системага китереп җыю процессында ирешә. Шулай ук Риза казый нәзаратга 100 ел дәвамында барлыкка килгән бай архивны җентекләп өйрәнә, тәртипкә сала. Очраган һәр кызыклы документтан үзенә күчермәләр, копияләр ала» [8].

Мәрҗанинең шифалы йогынтысы, табигый олы талант, хакыйкатькә төшенергә көчле омтылыш - болар барысы да Р.Фәхретдинне төп казыйлык вазыйфаларыннан читләштереп, фәнни эшчәнлек, дөньяви белемнәр ягына алып кереп китәләр. Шуның нәтиҗәсе буларак, бүген дә кыйммәтен югалтмаган био-библиографик хезмәте, ике томлык «Асар» барлыкка килә.

Моңа хәтле иске мәдрәсә педагогы, профессиональ рухани яссылыгында барган Р.Фәхретдин әнә шулай иҗатын баета, терләндерә бара. Ә инде 1905 елгы революциядән соң татар вакытлы матбугаты дөньяга килеп, бертуган

Рәмиевләр «Шура» журналы чыгара башлауга, Р. Фәхретдинне редактор итеп чакыралар һәм мәгърифәтче галим, руханилык дәрәҗәсен бөтенләй ташлап, Оренбургка күчеп килә һәм баш-аягы белән гыйльми, журналистлык эшчәнлегенә чума. Галим тормышындагы өченче борылыш, яңа этап әнә шулай башлана һәм, әйтергә кирәк, гомеренең иң бәрәкәтле чоры була бу аның өчен. «Баш мөхәррир буларак Риза Фәхретдинов бөтен көчен, зур оештыручы талантын журналның нәширләренең һәм үзенең халык агартуда булган максатын эшкә ашыруга багышлый» [5].

Р.Фәхретдин, әлбәттә һәм тарихчы, һәм журналист, һәм әдип, әмма шулай да ул эшчәнлеген укытучы һәм педагог буларак башлый. Галимнең эшчәнлеген өйрәнү һәм иҗат мирасын барлау буенча күп хезмәтләр куйган М.Рәхимкулова аның педагогика, тәрбия өлкәсендәге эшчәнлеге турында болай дип яза: «Бу юлдагы омтылышларын аның 80 гә якын тәрбия хакында язган китаплары ачыклый: «Гаилә», «Гакыйдә», «Нәсихәт 1», «Нәсихәт 2», «Нәсихәт 3», «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ата», «Шәкертлек әдәбе», «Әдәп тәгълим» һ.б... Р.Фәхретдин баланың туган көненнән башлап тәрбияләргә кирәк икәнлеген әйтә шул сәбәпле ата һәм ана булачак кешеләрнең тәрбиясенә дикъкать бирә» [5].

Гомумән алганда, Р.Фәхретдин - педагогикага караган 77 хезмәтнең авторы. Моңа өстәп, үзе баш мөхәррир булган «Шура» журналында чыккан мәкаләләрен дә әйтергә кирәк. Алар шулай ук тирән эчтәлекле һәм тәрбия фәненең бар якларын да колачлаулары белән аерылып торалар.

Мондый продуктив эшчәнлек галимнең үз өстендә өзлексез эшләве һәм үз-үзенә искиткеч таләпчәнлеге нәтиҗәсе. Әйтергә кирәк, Р.Фәхретдиннең башка татар галимнәре төсле Бохара, Сәмәрканд кебек Урта Азия мәдрәсәләренә барып белем алырга мөмкинлеге булмаган. Ләкин табигый сәләте һәм искиткеч тырышлыгы аркасында ул үз чорының күренекле һәм прогрессив карашлы галиме булып җитешә. Бернинди махсус уку йортларында укымыйча һәм методологик әзерлек алмыйча, ул тәрбия фәненең иң асыл сыйфатларына үтеп керә алган. Шул ук “Тәрҗемәи хәлем”дә мәгърифәтче

галим беренче педагогик карашларын, төшенчәләре формалашу турында болай яза: «Бу урында ишарә иткән вакыйгалар соңгы вакытларым өчен бөтенләй үк файдасыз булмаган, чөнки болардан үз балаларымны тәрбия итәр өчен ошбу кагыйдәләрне чыгардым:

1. Балаларның сораган нәрсәләрен камил игьтибар белән тыңлап, мөмкин кадәр җитди сурәттә дөрес һәм дә кыска вә ачык итеп аңлатырга тиешле икән.

2. Яшь балаларны иң элек укыта башлаганда, зиһеннәре төшенеп җитмәслек нәрсәләрне аңлату дөрес түгел икән.

3. Балаларга дәрес бирелә башлау белән үз акыллары илә төшенерлек дәрәҗәдә җәгърәфия вә тарих  фәннәреннән мәгълумат бирү фарыз икән» [7].

Күренгәнчә галим педагогикага җитди карый һәм яшьтән бирелгән тәрбиянең шәхес формалашуга йогынтысын аңлый. «Оясында ни күрсә очканында шул булыр», ди халык мәкале. Чыннан да, баланың дөнья турында, яхшылык һәм явызлык, гаделлек кебек әхлакый категорияләргә мөнәсәбәте гаиләдә формалаша. Бу очракта иң әһәмиятле рольне ата-ана уйный, чөнки күңелендә туган сораулары белән бала беренче чиратта аларга мөрәҗәгать итә. Мәктәпкәчә тәрбия педагогиканың иң җаваплы, әһәмиятле чоры булу белән бергә иң катлаулы һәм четерекле өлкәсе дә. Шәхес буларак бала 70% шул чорда формалаша. Бу хәл аның нерв системасы үзенчәлекләреннән, зур дөньяны үзе өчен үзе ачучы булып, бар нәрсәне дә яңалык дип кабул итүеннән килеп чыга. Нәкь менә мәктәпкәчә чорда кешенең мотивлар системасы формалаша, омтылышларын «ярый-ярамый» дигән иҗтимагый критерийлар белән чагыштыру процессы бара. Балага үз-үзенә ышаныч тудырырга ярдәм итәргә, дөньяны үзләштерүдә булышырга кирәк.

Р.Фәхретдин традицияләре бүгенге көндә дә үз дәвамын һәм үсешен тапты, һәм бу һаман да актуаль булып тора. Мәсәлән, татар теле, милләт язмышы, гаилә, ата-ана-бала мөнәсәбәте, туган җир, рухи һәм физик сәламәтлек, имин тормыш, һ.б. бүгенге әдәбиятта, мәдәнияттә, әдәби тәнкыйтьтә әле һаман калку итеп куела. Моны  без 2007 нче елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Җанга уелган уйлар» дигән хезмәттә дә

күрәбез. Ул Разил Вәлиевнең күренекле дәүләт эшлеклеләре, сәясәтчеләр, галимнәр, әдипләр һ.б. белән әңгәмәләреннән тора. Әңгәмәдә бик күп кеше катнаша.

Дәүләт эшлеклеләре, сәясәтчеләр белән әңгәмәсендә (Ф.Мөхәмәтшин, Р.Хәкимов, Ф.Сафиуллин, Ф.Мостафина һ.б.) икенче дәүләт теле статусын алуга ирешкән татар теленең дәүләт теле буларак гамәлгә ашуындагы кыенлыклар, милли телне саклау һәм үстерү мөмкинлекләре, милләт яшәеше, туган нигез кадере, милли традицияләрне кайтару һәм яңарту мәсьәләләре игътибар үзәгенә алына, милләтнең йөз аклыгы буларак мәчетләр яшәеше, төзелүе, аларның халыкка уңай йогынтысына ирешү проблемалары турында тирән фикерләр әйтелә.

Фәрит Мөхәммәтшинның Татарстаннан читтә яшәүче татарларны милләт вәкилләре буларак саклау турындагы сүзләре дулкынландыра. Һәр төбәктә тупланган татар өчен аерым игътибар кирәклеген ассызыклап ала Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Ф.Мөхәммәтшин. Үзеннән-үзе шундый сорау туа: аларны татар җанлы итеп тәрбияләү өчен, бүген кулланыла торган тулы җанлы, әдәби татар телен аларга нинди юллар белән җиткерергә соң? Татарстан җирлегендә яшәүче татарлар өчен мондый мөмкинлекләр бар: татарча сөйләүче радио, телевидение, татар телендә чыгучы газета-журналлар, татарча китаплар һ.б. Ә менә башка як татарлары өчен бу – авырырак мәсьәлә. Шуны искә алып, кыска дулкынлы радио оештырылган. Читтә яшәгән милләттәшләребезгә Бөтендөнья татар конгрессы аша, татарча компакт-дисклар, кассеталар, газеталар, уку-укыту әсбаплары, төрле әдәбият җибәрелеп тора. Ләкин татар милләтен, милли телләрне саклап калу өчен бу гына аз. Бу өлкәдә эшләнгән һәм эшләнәсе эшләребез байтак әле [3]. Шушы әңгәмәдә автор тарафыннан тагын бер мәсьәлә күтәрелә, ул да булса гаилә, ата-ана-бала мөнәсәбәтләре һәм моның милләтне саклаудагы роле. Ләкин ата-бабаларыбыз гадәтенә сеңгән әхлакый җаваплылык гаилә ягыннан да, дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан да онытылып бара икән. Ә бит милләтне саклауда гаиләнең роле әйтеп бетергесез. Р.Хакимов, К.Әмиров хәбәрләре чыны белән бүгенге татар

язмышына, ил - дөнья хәлләренә алып керә: СССР таркалу, Чечен хәлләре, югары пост әһеләре арасындагы мөнәсәбәтләр, Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләре, хокукый проблемалар... Сүз сөреше кайсы гына юлдан китмәсен, аның башы гаилә булып кала. Туган телне белү, хөрмәт итү, аралашу осталыгы, телне саклау, үз милләтең вәкиле булу – гаиләдән.

Әлегә кадәр татарны дин, мәгърифәт, китап, җыр, моң саклап калды, дибез дә бит, ә менә киләчәктә татарның, аның яшәешенең алга китүе өченниләр эшләргә кирәк соң? – дигән сорауга М.Госманов: “ Әгәр халык аерым бер халык булып яшәргә теләсә, аны – мәгърифәт, дин, аң, китап, җыр һәм моң яшәтәчәк. Әгәр теләмәсә, андыйлар бит һәрбер халыкта элек тә булган. Нинди генә казанышларга ирешелсә дә, кеше барыбер кеше булып калачак” – ди [3].

Т.Миңнуллин, Р.Фәйзуллин, Ф.Яруллин, З.Хәким, Р.Миңнуллин, М.Галиев һ.б. белән әңгәмәдә сүз әдәбият, мәдәният, сәнгать, алардагы үзгәрешләр, яңалыклар турында гына бармый, ә бәлки алар алдында торган проблемаларны чишү юллары хакында да фикер уртаклашу булып ала. Шунда “Әгәр дә әдәбиятның төп максаты милләтне алга чыгару, дөньяга таныту, баету икән, безнең бүгенге әдәбиятыбыз үзенең вазыйфасын тулы дәрәҗәдә үтиме соң?” – дигән сорау кузгатыла. Әлбәттә, күпмедер дәрәҗәдә үти: яңа китаплар басылып чыга, таратыла, төрле информация чараларыннан файдаланыла һ.б. Аерым кешеләр үз-үзләрен пропогандалыйлар... Ул гына җитми шул. Үзешчән сәнгать, үзешчән әдәбият, мәктәпләрдә укыту өчен дәреслекләр бик сирәк чыга, чыкканнары да сыек төзелә. Бигрәк тә әдәби ягы. Шушы яклап язучыларыбыз, әдәбият өлкәсендә эшлисе эшләр бик күп әле.

Ә бит гасыр башы мәдрәсәләренә хас булган уку-укыту эшендә югары нәтиҗәләргә ирешү өчен булган иң оптималь юлны, вариантны эзләү, үзләренә төшкән җаваплылыкны тоеп эш итү кебек күренешләр теләсә кайсы педагог галим өчен дә яхшы таныш.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Вәлиев Р.И. Сайланма әсәрләр: Публицистик язмалар, очерклар, мәкаләләр, әңгәмәләр. – Казан: Милли китап, 2000. – 672 б.

2. Вәлиев Р.И. Тормыш һәм иҗат юлы («Атаклы кешеләр» сериясеннән).- Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.  - 18 б.
3. Җанга уелган уйлар: Күренекле шәхесләр белән әңгәмәләр / төз. И.Һадиев; мөх. Г.Рәхим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 720 б.
4. Мәһдиев Р. Мәдрәсәләрдә китап киштәсе – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.
5. Рәхимкулова М. Ризаэтдин Фәхретдин. – Оренбург, 1998. - Б.59.
6. Фәхретдинов Р. Шәкертләр әдәбе. – Казан, 1904
7. Фәхретдин Р. Тәрҗемәи хәлем/ Фәнни-биографик җыентык. – Казан: Рухият, 1999. – 224 б.
8. Хәйруллин Ә. Кереш мәкалә// Китапта: Р.Фәхретдинов. Болгар вә Казан төрекләре: – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. - Б. 6.